ГЛАВНОЕ УПРАВЛЕНИЕ ВЕТЕРИНАРИИ КАБИНЕТА МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ БАШ ВЕТЕРИНАРИЯ ИДАРӘСЕ

ПРИКАЗ БОЕРЫК

04.05.2026 г. Казань № 46-од

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында» 2018 елның 12 апрелендәге 51-п номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссияләре турында» 2010 елның 25 августындагы ПУ-569 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссияләре хакындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында» 2018 елның 12 апрелендәге 51-п номерлы боерыгына (03.10.2022 ел, №123-од, 01.03.2023 ел, №23-од, 15.09.2023 ел, №114-од, 26.06.2024 ел, №53-од боерыклар нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

күрсәтелгән боерык белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе составын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәдә:

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2.1. Комиссия Ветеринария идарәсе боерыгы белән төзелә, аның нигезендә Комиссиянең составы һәм аның эш тәртибе раслана, Комиссия рәисе, аның урынбасары, секретаре билгеләп куела һәм Комиссиянең башка әгъзалары билгеләнә.

Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия. Комиссия рәисе булмый торганда аның вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.»;

2.2 пунктның «а» пунктчасында «(Комиссия рәисе),» сүзләреннән соң «Ветеринария идарәсендә дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче зат (Комиссия рәисе урынбасары)» сүзләрен өстәргә;

2.4 пунктта «Килештерү сорау алынган көннән алып 10 көн эчендә гамәлгә ашырыла.» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.1 пунктның «а» пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт хезмәткәре тарафыннан Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәдә каралган белешмәләрне төгәл яисә тулы итеп тапшырмавы турында;»;

3.11 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәгә туры китереп, дәүләт граждан хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең төгәл һәм тулы булуын билгеләргә;».

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
Баш ветеринария идарәсе башлыгы Т.М. Галиев

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең 12.04.2018 ел, №51-п боерыгы белән расланды
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең 04.05.2026 ел, №46-од боерыгы редакциясендә)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе составы

Комиссия рәисе:

| | |
|---|---|
| 1. Гыйниятуллин Илшат Тәлгать улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары |

Комиссия рәисе урынбасары:

| | |
|---|---|
| 2. Мотыйгуллин Габделхак Госман улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары |

Комиссия секретаре:

| | |
|---|---|
| 3. Гайфуллина Айгөл Ирек кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенең әйдәп баручы консультанты |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| 4. Заһидуллин Ленар Рәфыйкъ улы | «Казан дәүләт аграр университеты» ЮБ ФДБМУ «Н.Э.Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе» институты директоры вазыйфаларын вакытлыча башкаручы |
| 5. Жирнова Галина Ивановна | «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автономияле югары белем бирү учреждениесенең Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбенең оештыру бүлеге җитәкчесе урынбасары |
| 6. Шамшаева Гүзәл Рамил кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге башлыгы |

| | | |
|---|---|---|
| 7. | Шрша<br>Равия Бәдертдин кызы | Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенең коррупциягә каршы тикшерүләр бүлеге мөдире (килешү буенча) |
| 8. | Шәяхмәтов<br>Рөстәм Фәрит улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең хокук бүлеге башлыгы |